# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**Татарстан Республикасында килеп туган җәмгыяви-икътисадый вәзгыятькә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Президентына өстәмә вәкаләтләр бирү турында**

Икътисадтагы гамәлләрне кичектергесез кабул итүне арттыру, Татарстан Республикасында үзгәртеп коруларның барышын киләчәктә дә тәэмин итү, халыкны җәмгыяви яклауны көчәйтү максатларында һәм Татарстан Республикасы Конституциясенең 111 статьясы 17 пункты, 112 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Югары Советы КАРАР БИРӘ:

1 статья. Татарстан Республикасының финанс, икътисадый, җәмгыяви һәм хакими өлкәләрендә хокукый мөнәсәбәтләрне җайга салучы тиешле законнарны кабул иткәнче, Татарстан Республикасы Президентына санап үтелгән мәсьәләләр хакында указлар чыгару хокукы бирергә.

2 статья. Әлеге Закон басылып чыккан көненнән гамәлгә керә һәм 1995 елның 1 апреленә кадәр гамәлдә була.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1994 елның 8 июне